Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Советының егерме җиденче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
карары

24 октябрь, 2019 ел № 224

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль
хезмәт вазыйфалары реестрына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, идарә структурасын камилләштерү, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 205 номерлы карары белән расланган (2016 елның 3 мартындагы 36 номерлы, 2016 елның 27 декабрендәге 80 номерлы, 2017 елның 25 апрелендәге 97 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «2 нче бүлеккә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкаручы» кушымта нигезендә муниципаль хезмәтнең дүрт вазыйфасын кертергә.

2. Күрсәтелгән вазыйфаларның штат берәмлекләре эчтәлеген Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан бүлеп бирелә торган субвенцияләр һәм субсидияләр исәбеннән финансларга.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры турында» 2014 елның 21 ноябрендәге 205 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 27 декабрендәге 80 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И. М. Кашапов

Питрәч муниципаль районы Советы карарына кушымта
24 октябрь, 2019 ел № 224

## 2 Кисәк. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хезмәт вазыйфалары

| № пп | Вазыйфаның исеме | Төркемнәр исеме | Вазыйфалар саны |
|---|---|---|---|
| **балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе** | | | |
| 20 | баш белгеч | муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары | 1 |
| | | **ИТОГО** | **1** |
| **опека һәм попечительлек бүлеге** | | | |
| 21 | баш белгеч | муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары | 1 |
| 22 | әйдәп баручы белгеч | муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары | 2 |
| | | **БАРЛЫГЫ** | **3** |
| | | **БАРЫСЫ** | **4** |